**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**(III чакырылыш)**

**егерме җиденче утырыш**
**КАРАРЫ**

28 март 2019 ел **№ 172** Теләче авылы

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2013 елның 10 октябрендә кабул ителгән 170 санлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын раслау һәм аның хезмәткәрләренең чикләнгән санын билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы финанс министры урынбасарының 2018 елның 09 августындагы 03-82/6012 санлы хатын карап, 2003 елның 06 октябрендәге 131 санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның го муми принциплары турында» Федераль законга, 2007 елның 02 мартындагы 25 санлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы Федераль законга, Татарстан Республикасының Муни ципаль хезмәт турындагы кодексына, Татарстан Республикасының 2008 елның 20 мартындагы 7 санлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым вәкаләтләрен бирү турында»гы Законына туры китереп, **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2013 елның 10 октябрендә кабул ителгән 170 санлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын раслау һәм аның хезмәткәрләренең чикләнгән санын билгеләү турында»гы карарына (2013 елның 19. 12. № 188, 2014 елның 26. 05. № 212, 2014 елның 27. 11. № 234, 2015 елның 17. 04. № 263, 2016 елның 22. 04. № 47, 2018 елның 12. 04. № 128, 2018 елның 24. 08. № 142 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 1. 2019 елның 1 апреленнән Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хезмәт вазифалары реестрына Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы баш белгече өстәмә бер ставкасын кертергә.

1. 2. Карарның 2 пунктын түбәнднге редакциядә бирергә: «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләренең чикләнгән санын 34 штат берәмлегендә билгеләргә».

2. Карар гамәлдәге законнар нигезендә көченә керә.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының законнарны, хокук тәртибен һәм депутат этикасын саклау комитетына йөкләргә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы И.Ф. Зарипов